**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**«Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең Бәтке авыл җирлеге территориясендә терлекләр котыру авырулы булганга, аның иминлексезлеге сәбәпле кертелгән чикләү чараларын (карантинны) бетерү турында**

Котыру чиренә бирешүчән соңгы авыру хайванның үләксәсе юкка чыгарылган көннән 60 календарь көн узуы, эпизоотиягә каршы һәм профилактик чаралар уздырылу белән бәйле рәвештә, «Ветеринария турында» 1993 елның 14 маендагы 4979-I номерлы Россия Федерациясе Законының $3^1$ статьясы нигезендә **карар бирәм:**

1. «Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Бәтке авыл җирлеге Бәтке авылының Елга аръягы урамындагы 18 Б нче йортта урнашкан шәхси ярдәмче хуҗалык һәм «Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Бәтке авыл җирлеге территорияләрендә терлекләр котыру авырулы булганга, аларның иминлексезлеге сәбәпле кертелгән чикләү чараларын (карантинны) бетерергә.

2. Татарстан Республикасы Президентының «Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең Бәтке авыл җирлеге территориясендә хайваннар котыру авырулы булганга, аның иминлексезлеге сәбәпле чикләү чаралары (карантин) кертү турында 2021 елның 27 июлендәге ПУ-597 номерлы Указы үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ • АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2021 ел, 08 октябрь
№ ПУ-797